## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2022 елның 11 ноябрендәге Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Түбән Табын торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында**

**07 ноябрь 2023 ел** **№ 1**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча “2022 елның 11 ноябрендәге Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Түбән Табын торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2023 нче елның 26 октябренда узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1."Сез 2022 елның 11 ноябрендәге Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Түбән Табын торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” гы карарының 10 нчы пунктын түбәндәгечә күрсәтеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

“10. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә һәм дә ПКУ-0,8 (МТЗ) йөк төягече сатып алырга.”

**«РИЗА»** **«КАРШЫ».**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 121 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 73, бу 60% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 70 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 3 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Түбән Табын торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елның 11 ноябрендәге Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Түбән Табын торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” гы карарының 10 нчы пунктын түбәндәгечә күрсәтеп үзгәрешләр кертергә:

“10. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә һәм дә ПКУ-0,8 (МТЗ) йөк төягече сатып алырга.”

3. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

*Түбән Табын*
*авыл җирлеге башлыгы* *Р.Ш. Кыяметдинов*